КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 27 ноябрь г.Казань № 919

Татарстан Республикасының «Хайваннар авыруларына каршы көрәшү буенча республика станциясе» дәүләт бюджет учреждениесе исемен алыштыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының «Хайваннар авыруларына каршы көрәшү буенча республика станциясе» дәүләт бюджет учреждениесе исемен «Матди тәэмин итү станциясе» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – Матди тәэмин итү станциясе) дип алыштыру турындагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе тәкъдимен кабул итәргә

2. Матди тәэмин итү станциясе эшчәнлегенең төп максаты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе эшчәнлеген транспорт белән һәм матди-техник яктан тәэмин итү дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә:

Матди тәэмин итү станциясен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкарырга;

60 көн эчендә түбәндәгеләргә тиешле үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасының «Хайваннар авыруларына каршы көрәшү буенча республика станциясе» дәүләт бюджет учреждениесе уставына;

Татарстан Республикасының «Хайваннар авыруларына каршы көрәшү буенча республика станциясе» дәүләт бюджет учреждениесе өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) гамәлгә куючының дәүләт биремен.

4. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе белән берлектә, Татарстан Республикасының «Хайваннар авыруларына каршы көрәшү буенча республика станциясе» дәүләт бюджет

учреждениесе уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алганнан соң 30 көн эчендә бу карарның 1 нче пунктына яраклаштыру өлешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга Татарстан Республикасының кайбер дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2017 ел, 18 сентябрь, 700 нче карарына үзгәрешләр кертү хакындагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

5. Матди тәэмин итү станциясенең дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында әлеге максатларга күздә тотылган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин